Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы шәһәр тибындагы Апас бистәсе Башкарма комитеты карары

2025 ел, 23 гыйнвар № 56

Шәһәр тибындагы Апас бистәсе территориясендә Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасына үзгәрешләр кертү турында

"Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында" 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының шәһәр тибындагы Апас бистәсе башкарма комитеты карар итте:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының шәһәр тибындагы Апас бистәсе башкарма комитетының 2017 елның 30 гыйнварындагы 1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының шәһәр тибындагы Апас бистәсе территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасына (1 нче кушымта) түбәндәге эчтәлекле 5 нче юл өстәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 5 | шәһәр тибындагы Апас бистәсе, Кызыл Армия урамы ягыннан Үзәк паркка керү юлында (балалар поликлиникасы янында) | Азык-төлек һәм азык-төлек булмаган товарлар, яшелчәләр, җиләк-җимеш, соклар, эчемлекләр, җәмәгать туклануы | Автомагазин, автолавка, сәүдә палаткасы, лоток, контейнер, павильон | сәүдә | Кирәк булган саен |

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Л.Р. Сафина